ГЛАВА СТАРОКАРАЗЕРИКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с. Старый Каразерик, ул. Советская, д.12, 423965

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Иске Каразирек авылы, Совет урамы, 12 йорт, 423965

Тел.:(85593) 4-12-27, факс:4-12-27, e-mail: Skar.Utz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№ 4** **2020 ел 30 октябрь**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең Яңа Каразирек торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендә кабул ителгән 9 санлы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы "Иске Каразирек авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге башлыгы К А Р А Р И Т Т Е:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең Яңа Каразирек торак пунктында Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Яңа Каразирек авылы, Пионерская урамы, 18 йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасы янында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 11 ноябренә 13 сәгать 00 минутта билгеләргә.

Халык җыенына чыгарылган мәсьәләне расларга:

"2021 елда үзара салым кертүгә 400 сум күләмендә Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче студентлардан тыш, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юлларга сез ризамы:

- Яңа Каразирек авылы Пионерская урамына асфальт юл түшәү

« ӘЙЕ» «ЮК».

2. Иске Каразирек авыл җирлеге башкарма комитетына халык җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

3.Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», www.yutaza.tatar.ru веб-адрес буенча - Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

"Иске Каразирек авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Р.Вәлиев

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ